**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д.32г, с. Верхнее Стярле, 423314 Азнакаевского муниципального района Тел.факс (8-85592) 42-6-18,
**VSt..Azn@tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл жирлеге Советы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Советурамы, 32г, Югары Стәрлеавылы, 423314
Тел.факс (8-85592) 42-6-18,
**VSt.Azn@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«01» июль 2024 ел** **№ 5**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 30 мартындагы 4 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм территорияләр чикләрен билгеләү турында»гы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү һәм алкоголь продукциясен ваклап сату кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы 2013 елның 30 мартындагы 4 номерлы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына Азнакай шәһәр прокуратурасының 2024 елның 24 апрелендәге №02-08-2024/Прдп291-24-20920040 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2013 елның 30 мартындагы 4 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм территорияләр чикләрен билгеләү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.С.Сабирҗанова